ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

01.12.2020 | с. Коргуза | 02

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге  Егидерево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын   билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән  131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56нчы статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге  Егидерево авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 11нче декабренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне масларга:

«2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Егидерево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Егидерево авылында суүткәргечне ремонтлау
- Егидерево авылында су башнясын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Егидерево авылы, Центральная урамы, 28нче йорт адресы буенча урнашкан Егидерево фельдшер-акушерлык пункты бинасы янында гражданнар җыенын 9.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С. А. Сакин